ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КНӘЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел Татарстан поселогы № 10

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 декабрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 18 декабрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Кнәз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Кнәз авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Советының 2019 елның 05 декабрендәге 12/4 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 декабрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 18 декабрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Татарстан поселогы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрель 15.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 декабрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(Сосновый Бор т. п. яктырткычлар сатып алу, монтажлау һәм урам утларын урнаштыру);

«-урам яктырту эшләрен башкару(Сосновый Бор т. п. СИП - кабель сузу);

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Сосновый Бор т. п. юлларны ремонтлау);

«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтла у(Сосновый Бор т.п. сууткәргеч ремонтлау);

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 18 декабрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы гражданнар җыены карарына:

«- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(Сосновый Бор т. п. яктырткычлар сатып алу, монтажлау һәм урам утларын урнаштыру);

«-урам яктырту эшләрен башкару(Сосновый Бор т. п. СИП - кабель сузу);

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Сосновый Бор т. п. юлларны ремонтлау);

«-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтла у(Сосновый Бор т.п. сууткәргеч ремонтлау);

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Кнәз авыл җирлеге, Сосновый Бор поселогы, В.Максимова ур., 3 йорт (балалар мәйданчыгы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Хафизова